**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырья авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 12 ноябре** **№ 5**

**«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Куркино авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 22 ноябренә 12 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Куркино авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Куркино авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Куркино авылының Совет урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Куркино авылының Совет урамындагы буаны төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Куркино авылының Совет урамына тышкы күзәтү видеокамералары сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң ____ көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы В.В. Васильев

СОВЕТ НЫРЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1021607753111
ИНН 1623002336